| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН<br>ГЛАВА ЕГОРКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ЕГОРКИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |
|---|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | Егоркино ав. | **КАРАР** |
|---|---|---|

«13» октябрь 2025 ел № 1

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Нурлат муниципаль районы Егоркино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2025 елның 28 октябрендә 13 сәгать 30 минутка Садовая урамы буенча 2нче йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Егоркино авыл җирлегендә Садовая урамындагы 1-21, 2-24 йортларда яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2025 елның 28 октябрендә 14 сәгать 00 минутка Ленин урамы буенча 41нче йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Егоркино авыл җирлегендә Ленин урамы буенча 1-57, 2-16 йортларда яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. 2025 елның 28 октябрендә 14 сәгать 30 минутка Киров урамы буенча 19нчы йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Егоркино авыл җирлегендә Киров урамы буенча 1-31, 2-42 йортларда яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын уздыруны билгеләргә.

4. 2025 елның 28 октябрендә 15 сәгать 00 минутка Совет урамы буенча 10нчы йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Егоркино авыл җирлегендә Совет урамы буенча 1-31, 10-16, Чапаев урамында 1Б-15, 2-16, Үзәк урамы буенча 37-57, 64-78 йортларда яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын уздыруны билгеләргә.

5. 2025 елның 28 октябрендә 15 сәгать 30 минутка Ирек урамы буенча 28нче йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Егоркино авылында Ирек урамы буенча 2Б-40 йортларында, Беренче Май урамы буенча 2А-46.йортларда яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының бишенче этабын уздыруны билгеләргә.

6. 2025 елның 28 октябрендә 16 сәгать 00 минутта Егоркино авылы, Үзәк урам, 35нче йорт адресы буенча урнашкан Егоркино авыл мәдәният йортында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Егоркино авыл җирлеге Егоркино авылында 1-27, 2-64, Үзәк урамы; К.Маркс урамы буенча 1-45, 2-30; Ирек урамы буенча 1-9, 42-60; Беренче Май урамы буенча 1-17, 48-80 йортларда яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының алтынчы этабын уздыруны билгеләргә.

7. Халык җыенын үткәрү өчен Егоркино авылында яшәүчеләрнең исемлеген аеруга сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

8. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эшләре Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

9.Гражданнар җыенына чыгарылучы сорауны расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авыл җирлегенең Егоркино авылы территориясендә теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, 1 төркем инвалидлардан тыш, 2026 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?:

- урамнарны яктырту җайланмасы;
- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту.»

«РИЗА» «КАРШЫ».

10. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә) һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

11. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Егоркино авыл җирлеге башлыгы А.И. Борисов